# Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлегенең Балчыклы авылында 2023 елда гражданнардан үзара салым кертү турында гражданнар Җыенының карары

2022 елның 18 декабре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балчиклы авылында гражданнар җыены карар итте:

1.2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге Балчыклы авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ яшьтән 500,00 сум күләмендә үзара салым кертеп, өлешчә мобилизацияләү буенча мобилизацияләнгәннәрдән, аларның гаилә әгъзаларыннан һәм ата-аналарыннан гайре, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

1.Торак пункт эчендә чүп үләннәрен чабу (җәйге-көзге чор) (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

2. Торак пункттагы зиратка керү юлларын вак ташлау (сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эш өчен түләү);

3. Торак пунктта юлларны вак ташлау (сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эш өчен түләү);

4. Сууткәргечне ремонтлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

2. Адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итү:

- ТР, Кама Тамагы районы, Балчыклы авылы, Ленин урамы, 70, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Җыенда рәислек итүче, Татарстан Республикасы

Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас

авыл җирлеге башлыгы, Татарстан Республикасы

Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас

авыл җирлеге Советы рәисе Р.С.Сәгъдиев